**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 10 декабрь № 937

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Идел буе федераль округында һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1103 нче карары белән расланган Идел буе федераль округында һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Идел буе федераль округында һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1103 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 сентябрь, 649 нчы, 2015 ел, 12 март, 147 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Идел буе федераль округында һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге Тәртипкә теркәлгән 2015 елга Идел буе федераль округы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе субъектлары аэропортларына

Татарстан Республикасы аэропортларыннан һава транспорты белән пассажирлар йөртү маршрутлары исемлегенә түбәндәге эчтәлекле 8 нче пункт өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «8. | Казан | Түбән Новгород | 7 | 2 975 | 40 453». |

2. Бу карарның гамәле 2015 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына авиатранспортта пассажирлар йөртүче белән 2015 елда Идел буе федераль округында һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү турында шартнамә төзүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\937.docx